МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.05.2019 г.Казань № 108/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында

”Норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын коррупциягә каршы экспертизалау турында” 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең ”Норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын коррупциягә каршы экспертизалау турында” 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ”Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары нигезендә БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Эш башкару һәм контроль бүлегенә әлеге боерыкны, ул Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәлгәннән соң, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының барлык структур бүлекчәләренә җиткерергә.

3. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының ”Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру турында” 2015 елның 17 мартындагы 47/2-пр номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен үзем тикшереп торам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министр урынбасары -
министр М.Г. Әхмәтов

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру**

# ТӘРТИБЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба - Министрлык) норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына, шулай ук Министрлык тарафыннан эшләнә торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларына (алга таба - актлар, актлар проектлары) коррупциягә каршы экспертиза уздыру һәм коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу процедурасын билгели.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза ”Норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын коррупциягә каршы экспертизалау турында” 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең ”Норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын коррупциягә каршы экспертизалау турында” 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ”Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2017 елның 15 августындагы 580 карары, шулай ук әлеге Тәртип нигезендә үткәрелә.

1.3. Коррупциягә каршы экспертизаның максаты актларда һәм актлар проектларында коррупциячел факторларны ачыклаудан һәм аннары аларны бетерүдән гыйбарәт.

1.4. Коррупциягә каршы экспертиза үз көчләрен югалткан яисә кире кагылган норматив хокукый актларга уздырылмый.

## 11. Актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру

2.1. Актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза Министрлыкта коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен җаваплы вазыйыаи зат (алга таба - вазыйфаи зат) тарафыннан уздырыла.

Ул вазыйфаи зат шулай ук Министрлыкта коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналын (алга таба - Журнал) алып абру өчен дә җаваплы була (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта).

Вазыйфаи зат Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры (алга таба - министр) тарафыннан билгеләнә.

2.2. Коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен актлар һәм актлар проектлары шул актны кабул итү инициативасын күрсәткән структур бүлекчә (акт проектын эшләү өчен җаваплы) җитәкчесенә, вазыйфаи затка җибәрелә.

2.3. Коррупциягә каршы экспертиза Журналда теркәлгән көннән ун көн эчендә уздырыла.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта формасы буенча бәяләмә чыгарыла, анда түбәндәге белешмәләр чагылдырыла:

экспертизага бирелгән актның реквизитлары акта (акт проектының исеме); актта (акт проектында) коррупциячел факторларның булу-булмавы турында;

коррупциячел факторлар булган (булган очракта) актның (акт проектының) конкрет нигезләмәләре;

коррупциячеллекне бетерү өчен (коррупциячел факторларн ачыкланганда) акт (акт проекты) нигезләмләрен үзгәртү йә аерым нигезләмәләрне төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр.

2.5. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча төзелгән, вазыйфаи зат тарафыннан әзерләнгән һәм имзаланган бәяләмә ул төзелгән көндә бу актны (акт проектын) җибәргән структур бүлекчәгә тапшырыла.

2.6. Минстрлыкның актны (акт проектын) әзерләүдә җаваплы структур бүлкчәсе, коррупциягә каршы экспертиза уздырганада ачыкланган коррупциячел факторлар күрсәтелгән бәяләмәне алгач, аларны министр белән килештереп, өч көн эчендә норматив хокукый акт проектын эшләп бетерә һәм эшләнеп беткән норматив хокукый акт проектын вазыйфаи затка кабат карау өчен җибәрә.

Әгәр экспертизага җибәрелгән актта (акт проектында) коррупциячел факторлар булмаса, актны (акт проектын) эшләүдә җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе актны (акт проектын) структур бүлекчәләрнең

кызыксынучы җитәкчеләренең имзалары белән министрга кул кую өчен җибәрә яисә актны (акт проектын) кызыксынучы органнарга һәм оешмаларга килештерү өчен җибәрүне тәэмин итә.

## III. Актларга һәм актлар проектларына коррупцигә каршы бәйсез экспертиза уздыру

3.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектларына Министрлыкның рәсми басылып чыккан һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында http://agro@tatarstan.ru (алга таба - сайт) яисә мәгълүмат ресурсында Татарстан дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм җәмәгатьчелек фикерен алу максатында урнаштырылган норматив хокукый актлары керә. Татарстан дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм җәмәгатьчелек фикерен алу максатында бердәм төбәк интернет-порталы (алга таба - бердәм төбәк интернет-порталы) тарафыннан билгеләнгән мәгълүмат ресурсында урнаштырылган, Министрлык тарафыннан эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары керә.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр яисә конфиденциаль характердагы белешмәләр булган норматив хокукый актларга, норматив хокукый актлар проектларына уздырылмый.

3.1. Министрлык тарафыннан эшләнеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Дәүләт Думасына кертелә торган федераль законнар проектларына, Татарстан Республикасы законнары проектларына, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен аларны Министрлык «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында һәм бердәм төбәк интернет-порталында аларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы башкарма органнарына, башка органнарга һәм оешмаларга килештерү өчен җибәрү көненә туры килә торган эш көне дәвамында урнаштыра.

3.2. Министрлык актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен Министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе акт проектын карау өчен вазыйфаи затка җибәрү көненә туры килә торган эш көне дәвамында акт проектын сайта һәм бердәм төбәк интернет-порталында урнаштыра, анда эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адрес (шул исәптән электрон почта адресы), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алу башлану һәм тәмамлану датасы күрсәтелә.

3.3. Сайтта урнаштырылган актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру срогы алар урнаштырылган көннән кимендә эш көне була.

3.4. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча Министрлыкка билгеләнгән срок чикләрендә кергән бәяләмә (алга таба - бәяләмә) кергән көннән соң килүче эш көнненән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында теркәлә һәм Министрлыкның актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсенә карау өчен җибәрелә.

3.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә күрсәтмә характерында була. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә ул теркәлгән көннән 15 көн эчендә, әлеге Тәртипнең 3.7 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, Министрлык тарафыннан катгый рәвештә каралырга тиеш.

Карау нәтиҗәләре буенча коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырган юридик яисә физик затка дәлилле җавап җибәрелә (бәяләмәдә ачыкланган коррупциячел факторлар турында мәгълүмат яисә ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү ысуллары турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш), анда коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу һәм (яисә) норматив хокукый актта яки норматив хокукый акт проектында ачыкланган коррупциячел фактор белән килешмәү сәбәбе күрсәтелә.

3.6. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә түбәндәгеләр каралмый:

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру буенча экспертлар буларак Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан аккредитацияләнмәгән юридик яисә физик затлар әзерләгән норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектлары;

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан расланган формага туры килми торган норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектлары.

Әлеге Тәртипнең 3.7 пунтындагы өченче абзацында күрсәтелгән очракта, Министрлык андый бәяләмәне ул теркәлгән көннән 15 көннән дә соңга калмыйча, сәбәпләре күрсәтелеп, кире кайтарыла.

3.7. Акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырганда ачыкланган коррупциячел факторлар проект актын эшләп бетерү стадиясендә бетерелә.

Акт проектына коррупциягә каршы экспертиза уздырганнан соң аны эшләүче тарафыннан үзгәрешләр кертелгән очракта, акт проектына кабат коррупциягә каршы экспертиза уздырылырга тиеш.

3.8. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән искәрмәләр бетерелгәннән һәм тәкъдимнәр исәпкә алынганнан соң, Министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе акт проектын кабат карау өчен вазыйфаи затка тапшыра, аңа коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча кергән бәяләмәләр өстәлеп бирелә. Кабат карау өч көн эчендә башкарыла.

3.9. Әгәр актта коррупциячел факторлар ачыкланса, Министрлыкның әлеге актны әзерләгән структур бүлекчәсе бәяләмә Министрлыкта теркәлгән көннән өч көн эчендә актка үзгәрешләр кертү буенча яисә аны үз көчен югалткан дип тану турында чаралар күрә.

3.10. Актны эшләүче коррупциягә каршы экспертизаның, шул исәптән бәйсез экспертизаның үзе эшләгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Дәүләт Думасына кертелә торган федераль законнар проектларында, Татарстан Республикасы законнары проектларында, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциячел факторларның булуы турындагы нәтиҗәләр белән килешмәгән очракта, аларны эшләүче күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламентында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә, коррупциягә каршы экспертизаның, шул исәптән бәйсез экспертизаның бәяләмәсе һәм аның риза булмавын нигезләгән аңлатма язуы да бирелә. 5

## IV. Норматив хокукый актлар проектларын җәмәгатьчелек фикер алышуына чыгару

4.1. Министрлык эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларын җәмәгатьчелек фикер алышуына чыгаруны тәэмин итә.

4.2. Җәмәгатьчелек фикер алышуы максатларында норматив хокукый актлар проектлары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм җәмәгатьчелек фикер алышуына чыгару өчен бердәм төбәк интернет-порталы тарафыннан билгеләнгән Татарстан Республикасы рәсми порталында (Мәгълүмат ресурсы) (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштырылалар.

4.3. Җәмәгатьчелек фикер алышуы өчен Мәгълүмат ресурсында гражданнарның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы норматив хокукый актлар проектлары урнаштырыла.

4.4. Җәмәгатьчелек фикер алышуы өчен түбәндәгеләр урнаштырылмый:

дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр яисә конфиденциаль характердагы белешмәләр булган норматив хокукый актлар проектлары;

актларның (аларның структур берәмлекләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында норматив хокуый актлар проектлары;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары йөкләмәләрендә билгеләнгән эшләү срогы җәмәгатьчелек фикер алышуының минималь срогыннан кимрәк булган (Мәгълүмат ресурсында урнаштырылган көннән биш эш көненнән азрак) булган норматив хокукый актлар проектлары;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә яисә чыгымнарына тәэсир итә торган норматив хокукый актлар проектлары, Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тәэмин итүгә бәйле норматив хокукый актлар проектлары;

дәүләт хакимите органнарының терроризмга каршы көрәшкә, шул исәптән терроризмны финанслауга бәйле чаралар башкарганда, аларның эшчәнлеген һәм үзара хезмәттәшлеген оештыру, тәэмин итү мәсьәләләрен регламентлаучы норматив хокукый актлар;

Татарстан Республикасы норматив хокуый актларын законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән норматив хокуый актлар проектлары;

суд карарларын, прокурор карарлары актларын, контроль-счет органнарының күрсәтмәләрен гамәлгә ашыру максатларында әзерләнгән норматив хокукый актлар проектлары;

дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентлары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары проектлары;

статистика күзәтчелеге формаларын раслау турында норматив хокукый актлар проектлары;

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының гамәлдә булуын туктатып тору турындагы норматив хокукый актлар проектлары.

4.5. Норматив хокукый актлар проектларын җәмәгатьчелек фикер алышуы өчен урнаштырганда проектны эшләү инициаторы булган структур бүлекчә тәкъдинәр һәм искәрмәләр юллау өчен адрес (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук җәмәгатьчелек фикер алышуы срогының башлану һәм тәмамлану датасын күрсәтә.

4.6. Норматив хокукый актлар проектлары буенча аларны эшләүче тарафыннан билгеләнә торган җәмәгатьчелек фикер алышуы срогы Мәгълүмат ресурсында урнаштырылган көннән биш эш көненнән дә кимрәк була алмый.

4.7. Проектны эшләү инициаторы булган структур бүлекчә тарафыннан җәмәгатьчелек фикер алышу нәтиҗәләре буенча норматив хокукый акт проектын эшләп бетерү турында карар кабул ителгән очракта, эшләнеп беткән норматив хокукый акт проекты да җәмәгатьчелек фикер алышуы өчен урнаштырыла.

4.8. Норматив хокукый актлар проектларын Мәгълүмат ресурсында урнаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру срогы, җәмәгатьчелек фикер алышуы срогы тәмамланганнан соң 30 көн эчендә актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы зат коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру барышында ачыкланган факторлар турында, җәмәгатьчелек фикер алышуы барышында кергән тәкъдимнәр турында җыелма мәгълүмат урнаштыра, аларны карау нәтиҗәләре әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтадагы рәвеш буенча күрсәтелә.

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек
министрлыгының норматив
хокукый актларына
һәм норматив хокукый актлар
проектларына
коррупциягә каршы
экспертиза уздыру тәртибенә
1 нче кушымта

**Коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналы**

| Актның (акт проекты-ның) экспер-тизага кергән датасы | Актны (акт проектын) тапшырган структур бүлекчә | Актның (акт проектының) исеме | Коррупциячел нормаларның булу-булмавы | Бәяләмә чыгару датасы | Актлар проектларына карата искәрмәләр (кабат экспертиза уздыру турында мәгълүмат, кабат экспертиза уздыру нәтиҗәләре буенча бәяләмә чыгару датасы) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек
министрлыгының норматив
хокукый актларына
һәм норматив хокукый актлар
проектларына
коррупциягә каршы
экспертиза уздыру тәртибенә

2 нче кушымта

**Коррупциягә каршы**
**экспертиза бәяләмәсе**

(норматив хокуый актның реквизитлары яисә норматив хокукый акт проектының исеме)

”Норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын коррупциягә каршы экспертизалау турында” 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, , Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ”Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең ”Норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын коррупциягә каршы экспертизалау турында” 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын коррупциягә каршы экспертизалау методикасы нигезендә актка коррупциягә каршы экспериза уздырылды, ул андагы коррупциячел факторларны ачыклау һәм, булган очракта, аларны бетерү масатында эшләнде.

Проектта коррупциячел нормаларның булуы яисә булмавы:

Акт проектының коррупциячел нормалар булган конкрет нигезләмәләре:

Коррупциячеллекне бетерү өчен формулировкаларны үзгәртү йә аерым нормаларны төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр:

Вазыйфаи зат ____________ ______________________________
(имза) (Фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек
министрлыгының норматив
хокукый актларына
һәм норматив хокукый актлар
проектларына
коррупциягә каршы
экспертиза уздыру тәртибенә

3 нче кушымта

**Проектка коррупциягә каршы экспертиза уздыру һәм (яисә) җәмәгатьчелек фикер алышуы йомгаклары буенча**
**ҖЫЕЛМА МӘГЪЛҮМАТ**

(норматив хокукый актның төре, норматив хокукый акт проектының исеме)

| Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза | | | |
|---|---|---|---|
| Т/С № | Эксперт (Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булса) аккредитация турында күрсәтмә реквизитлары) | Ачыкланган коррупциячел фактор | Акты әзерләүченең комментарийлары |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмәгатьчелек фикер алышуы | | | |
| Т/С № | Фикер алышуда катнашучы (Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булса), электрон почта адресы) | Фикер алышуда катнашучының позициясе | Акты әзерләүченең комментарийлары |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

| | |
|---|---|
| Кергән  тәкъдимнәрнең  гомуми  саны | |
| Исәпкә  алынган тәкъдимнәрнең  гомуми  саны | |
| Өоешчә исәпкә  алынган тәкъдимнәрнең  гомуми  саны | |
| Исәпкә  алынмаган тәкъдимнәрнең  гомуми  саны | |